| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.10.2024 Казан ш. № 615-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан карарлар кабул ителү тәртибе турында” 08.05.2020 № 279-пр боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы структурасына үзгәрешләр кертелү сәбәпле б о е р а м:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Җир

һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан карарлар кабул ителү тәртибе турында” 08.05.2020 № 279-пр боерыгына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 20.07.2020 № 465-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) кертелгән тәкъдим ителгән үзгәрешләне расларга.

**Министр** **А.Р.Кадыйров**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
18.10.2024 № 615-пр
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан карарлар кабул ителү тәртибе турында” 08.05.2020 № 279-пр боерыгына кертелгән
үзгәрешләр

Боерык белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан карарлар кабул ителү тәртибен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан карарлар кабул итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан карарлар кабул итү кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

Түләттерү өметсез дип таныла торган бурычлар суммасына юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм физик затларның Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве буенча, вакытында түләмәгән өчен законнар нигезендә саналган, ләкин билгеләнгән вакытта түләнмәгән пенялар буенча бурычлары, шулай ук, административ штрафлар керә.

2. Татарстан Республикасы бюджетына Министрлык администраторлык иткән түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында

караркабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

2.1. Физик затның – Татарстан Республикасы бюджетына түләүченең вафаты яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителгәндә;

2.2. Гражданинның, шәхси эшмәкәрнең «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге № 127-ФЗ Федераль закон нигезендә бюджетка түләүләр буенча бурычлы затның мөлкәте җитмәү сәбәпле түләнмәгән бурычлары өлешендә банкрот дип танылу процедурасы тәмамлануы;

2.3. Татарстан Республикасы бюджетына түләүче оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманың гамәлгә куючылары (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләнмәгән бурычы өчен бетерелүе очрагында;

2.4. Штрафка яки суд карары белән җәзага тартылганнарга мөнәсәбәтле амнистия турында яки аклау турында актлар куллану нигезендә яки сул карары нигезендә Министрлык бюджетка түләүләр буенча бурычны түләттерү мөмкинлеген югалткан очракта, шул исәптән, түләттерү өчен билгеләнгән срокның вакыты чыгу аркасында;

2.5. Суд приставы-башкаручы тарафыннан «Башкару производствосы турында» 2007 елның 2 октябрендәге № 229-ФЗ Федераль законның 46 статьясының 1 өлешендәге 3 яки 4 пунктында күздә тотылган нигезләр буенча башкару производствосының тәмамлануы һәм түләтүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда, бюджетка түләүләр буенча бурычның барлыкка килү датасыннан биш елдан күбрәк вакыт узганда, түбәндәге очракларда:

2.6. Бурычлыны банкрот дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылганда яки банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турында эш производствосы туктатылганда;

2.7. Юридик затны регистрация ясаучы орган карары буенча Юридик затларның бердәм дәүләт реестрынннан чыгарган һәм суд приставы-башкаручы тарафыннан «Башкару производствосы турында» 2007 елның 2 октябрендәге № 229-ФЗ Федераль законның 46 статьясының 1 өлешендә 3 яи 4 пунктларында күздә тотылган нигезләр буенча башкару производствосының тәмамлануы һәм түләтүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда - оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм әлеге оешманың гамәлгә куючылары (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда түләп булмаган бюджетка түләүләр буенча бурычлары өлешенә карый. Регистрация ясаучы органның юридик затны «Юридик затларны һәм хосусый эшмәкәрләрне дәүләт теркәве турында» 2001 елның 8 августындагы № 129-ФЗ Федераль законына туры китереп Юридик затларны бердәм дәүләт реестрыннан

чыгару турында карары гамәлдә түгел дип танылса, әлеге подпункт нигезендә түләү өметсез лир танылган бурычлар бюджет (бухгалтер) исәп-хисабында торгызыла.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган очраклар белән бергә, Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы кодексында каралганча, административ җәза билгеләнү турындагы карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан административ җәза билгеләнү турындагы карарны башкаруны туктату турында карар чыгарылган очракта, үз вакытында түләнмәгән административ штрафлар түләттерүгә өметсез дип таныла.

4. Әлеге Тәртипнең 2 пунктының 2.1 подпунктында күрсәтелгән очракта Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар түбәндәгеләр нигезендә кабул ителә:

Министрлыкның финанслар һәм дәүләт заказы бүлеге тарафыннан әзерләнгән баланс (забаланс) счетында исәпкә алынган Татарстан Республикасы бюджетына кайтарыласы бурычлар суммасы турында белешмәләр, әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында китерелгән формада (алга таба – бурычлар суммасы турында белешмә);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча дебит бурычларын кайтарттыру буенча Министрлык вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган чаралардан чыгып Татарстан Республикасы бюджетына бурычларны түләттерүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясына туры китереп билгеләнгән пеня һәм штрафлар турында, һәрбер юридик зат, шәхси эшмәкәр яки физик зат буенча Министрлыкның әлеге админитраторлана торган керем чыганагы беркетелгән структур бүлекчәсенең, (алга таба – кураторлык иткән бүлек) хокук идарәсе белән берлектә әзерләнгән белешмәләр (алга таба – күрелгән чаралар турында белешмә);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүче физик затның үлемен раслый торган яисә аның үлгән дип игълан ителү фактын раслаган вәкаләтле органнан алынган документ.

5. Әлеге Тәртипнең 2 пункты 2.2 подпунктында күрсәтелгән очракта Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар түбәндәгеләр нигезендә кабул ителә:

бурычлар суммасы турында белешмәләр;

күрелгән чаралар турында белешмәләр;

хосусый эшмәкәр булган бюджетка түләүче гражданинның мөлкәте реализацияләнеп бетүе яки конкурс производствосы тәмамлануы турында суд акты;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүче физик затның хосусый эшмәкәрнең мал-мөлкәтсез (банкрот) дип танылуына суд акты кабул ителүенә

бәйле рәвештә эшчәнлегенең туктатылуы турында Хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестры мәгълүматларын эченә алган документ;

бюджетка түләүче гражданинның мөлкәте реализацияләнеп бетүе яки конкурс производствосы тәмамлануы турында суд акты;

гражданинның судтан тыш банкрот дип танылу процедурасы тәмамлануы турында Банкротлык турында мәгълүматлар бердәм федераль реестрыннан белешмә булган документ.

6. Әлеге Тәртипнең 2 пункты 2.3 подпунктында күрсәтелгән очракта Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар түбәндәгеләр нигезендә кабул ителә:

бурычлар суммасы турында белешмәләр;

күрелгән чаралар турында белешмәләр;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче оешманың ликвидацияләнүе сәбәпле эшчәнлеге туктатылуы турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестры мәгълүматларын үз эченә алган документ.

7. Әлеге Тәртипнең 2 пункты 2.4 подпунктында күрсәтелгән очракта Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар түбәндәгеләр нигезендә кабул ителә:

бурычлар суммасы турында белешмәләр;

күрелгән чаралар турында белешмәләр;

бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр буенча бурычны түләттерү мөмкинлеген югалтуына китергән штраф яки суд акты рәвешендә җәзага тартылганнарга мөнәсәбәтле амнистия турында яки аклау турында суд акты, шул исәптән түләттерү өчен билгеләнгән срокның вакыты чыгу сәбәпле.

8. Әлеге Тәртипнең 2 пункты 2.5 подпунктында күрсәтелгән очракта Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар түбәндәгеләр нигезендә кабул ителә:

бурычлар суммасы турында белешмәләр;

күрелгән чаралар турында белешмәләр;

«Башкару производствосы турында» 2007 елның 2 октябрендәге № 229-ФЗ Федераль законның 46 статьясының 1 өлешендәге 3 яки 4 пунктында күздә тотылган нигезләр буенча башкару производствосының тәмамлануы һәм түләтүчегә башкару документын кире кайтару турында суд приставы-башкаручының карары.

9. Әлеге Тәртипнең 2 пункты 2.6 подпунктында күрсәтелгән очракта Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар түбәндәгеләр нигезендә кабул ителә:

бурычлар суммасы турында белешмәләр;

күрелгән чаралар турында белешмәләр;

бурычлыны хәлле булмавы (банкротлыгы) танылу турында гаризаны кире кайтару турында яки банкротлык турында эш процедураларын үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен акчалар булмау сәбәпле банкротлык турында производствоны туктату турында суд акты.

10. Әлеге Тәртипнең 2 пункты 2.7 подпунктында күрсәтелгән очракта Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар түбәндәгеләр нигезендә кабул ителә:

бурычлар суммасы турында белешмәләр;

күрелгән чаралар турында белешмәләр;

регистрация ясаучы орган карары буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлының - юридик затның күрсәтелгән ресстрдан чыгарылуы турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестры мәгълүматларын үз эченә алган документ;

бурычлыны хәлле булмавы (банкротлыгы) танылу турында гаризаны кире кайтару турында яки банкротлык турында эш процедураларын үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен акчалар булмау сәбәпле банкротлык турында производствоны туктату турында суд акты.

11. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән очракта Бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар түбәндәгеләр нигезендә кабул ителә:

бурычлар суммасы турында белешмәләр;

күрелгән чаралар турында белешмәләр;

административ җәза билгеләнү турындагы карарның башкарылуы туктатылу турында карар.

12. Тапшырылган документларның күчермәләре тиешле тәртиптә расланган булырга тиеш.

13. Министрлыкка әлеге Тәртипнең 2 яки 3 пунктларында каралган очрак килеп чыкканлыгы турында турында хәбәр килеп ирешкәннән соң 22 эш көне эчендә кураторлык иткән бүлек тарафыннан әлеге Тәртипнең 4-11 пунктларына туры китереп, Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану нигезләрен раслаган документлар пакеты җыела, һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы керемнәрнең төп администраторы булган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны кичерү комиссиясенә (алга таба – Комиссия) юллана. Документлар Комиссия карамагына квартал саен юллана.

14. Комиссия Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы керемнәрнең төп администраторы булган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны кичерү комиссиясе турында нигезләмә

нигезендә эш итә, аның составы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы боерыгы белән раслана.

15. Документлар пакетын карап чыкканнан соң Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип таныргa – әлеге Тәртипнең 2 яки 3 пунктында күрсәтелгән нигезләр һәм (яки) әлеге Тәртипнең 4-11 пунктларында күрсәтелгән документлар булганда;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип танудан баш тартырга - әлеге Тәртипнең 2 яки 3 пунктында күрсәтелгән нигезләр һәм (яки) әлеге Тәртипнең 4-11 пунктларында күрсәтелгән документлар булмаган очракта. Әлеге карар Татарстан Республикасы бюджетына бурычларны түләттерүне өметсез дип тану турында карарны кабат карау өчен тоткарлык тудырмый.

16. Комиссиянең бурычларны түләттерүне өметсез дип тану турындагы карары әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында китерелгән форма буенча акт итеп формалаштырыла һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

юридик затның тулы атамасы / шәхси эшмәкәрнең, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса);

салым түләүченең идентификацион номеры, төп дәүләт регистрация номеры, юридик затны салым түләүче исәбенә куюның сәбәбе коды / шәхси эшмәкәрнең, физик затның салым түләүче идентификацион номеры (булса);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар килеп чыккан түләү турында белешмә;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар исәпләнә торган Россия Федерациясе бюджетлары керемнәренең классификация коды, аның атамасы;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар суммасы;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар бурычы суммасы;

дата принятия решения о признании безнадежной к взысканию задолженности по платежам в бюджет Республики татарстан;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерүне өметсез дип тану турында карар кабул ителгән дата;

Комиссия әгъзалары имзалары.

17. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры раслаган акт Министрлыкның финанслар һәм дәүләт заказы бүлегенең бюджет (бухгалтер) хисабыннан Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен файдаланган өчен Татарстан Республикасы бюджетына

түләүләр буенча бурычларны кичерү өчен нигез булып тора.

2. Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы керемнәрнең төп администраторы булган Татарстан Республикасы бюджетына түләү бурычларын кичерү буенча комиссия нигезләмәсендә:

1 пунктта «(алга таба – Комиссия)» сүзен «(алга таба тиешенчә – Комиссия, Министрлык)» сүзләре белән, «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» сүзләрен «Министрлык» сүзе белән алмаштырырга;

3 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» сүзләрен «Министрлык» сүзе белән алмаштырырга;

икенче абзаце «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» сүзләрен «Министрлык» сүзе белән алмаштырырга;

дүртенче абзацның 4 пунктында «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» сүзләрен «Министрлык» сүзе белән алмаштырырга;

6 пунктны «, ләкин кварталга бер тапкырдан да сирәгрәк түгел.» сүзләре белән тулыландырырга;

9 – 14 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Комиссия Татарстан Республикасы бюджетына түләү бурычларын кайтару өметсез булуын тану мәсьәләсе буенча бирелгән документлар пакетын Комиссия рәисенә кергән көннән башлап 10 эш көне эчендә карап чыга.

10. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән катнашкан әгъзаларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда утырышка рәислек итүченең тавышы хәлиткеч дип санала.

Комиссия утырышында кабул ителгән карарлар Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылыш таба, утырышта рәислек итх һәм сәркатип тарафыннан имзалана.

11. Комиссия утырышы нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип танылган очракта Комиссия утырышы үткәннән соң ун эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә.

12. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү өметсез дип тану турында карар Комиссия утырышы үткәннән соң ун эш көне эчендә акт буларак рәсмиләштерелә.

Акт ике данәдә төзелә, утырышка рәислек итүченең һәм Комиссиянең утырышта катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

13. Имзаланганнан соң биш эш көне эчендә акт Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры тарафыннан раслана.

14. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны кичерү мөмкин түгеллеге турында карар чыгарылган очракта, Комиссия документлар пакетын бурычларны түләттерү буенча өстәмә чаралар күрү өчен Министрлыкның кураторлык иткән бүлегенә кайтара.»;

15 пунктта «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 юлның икенче баганасында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы төп администраторы булган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен кураторлык иткән бүлекләр исемлегендә «, дәүләт мөлкәтен реализацияләү һәм инвестиция проектларын тормышка ашыру» сүзләрен словами «һәм дәүләт мөлкәтен реализацияләү» сүзләре белән алмаштырырга.